**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур, 1 А

**СОВЕТ АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Айбаш , ул. Центральная, д. 1 А

тел./факс 8(84365) 6-07-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**26 октябрь 2020 ел** **№ 6**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Айбаш авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 декабрендәге 169 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1. өлеш белән тулыландырырга:

«1.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«инициатив проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Айбаш авыл җирлеге Башлыгы Р.Р. Сафиуллин